РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2026 елның 15 апреле № 17

Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама шәһәренең бюджет-финанс сәясәтен билгеләүче нигезләмәләрне раслау турында» 2009 елның 28 гыйнварындагы 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама шәһәренең бюджет-финанс сәясәтен билгеләүче нигезләмәләрне раслау турында» 2009 елның 28 гыйнварындагы 5 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымта карарына

14 статьяның 2 пунктының җиденче абзацында «Россия Федерациясе бюджет системасының, «сүзләреннән соң», шул исәптән дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне арендага алган һәм реализацияләгән өчен түләүләрне,» сүзләрен өстәргә»;

34 статьяның 4 пунктының өченче абзацында «һәм гамәлгә ашырганда» сүзләрен «, дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны үзәкләштерү нәтиҗәсендә бюджет акчаларын экономияләү барлыкка килгәч һәм гамәлгә ашырганда»сүзләренә алмаштырырга.;

34 статьяның 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

« -бюджет ассигнованиеләре ашыгыч гуманитар җавап бирү, гуманитар ярдәм йөкләрен китерү, халыкны эвакуацияләү, гадәттән тыш хәлләрне бетерү чараларын финанс белән тәэмин итүгә яңадан бүленгән очракта»;

45 статья исемендә «төзүне» сүзеннән соң «, тапшыруны һәм раслауны»сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре Уставында билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының бюджет сәясәте, икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры Р.И. Беляев